ГЛАВА КАНАШСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ ВЕРХНЕУСЛОНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ ЮГАРЫ ОСЛАН МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫҢ КАНАШ АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ БАШЛЫГЫ

Тел.: (84379) 30-1-48, факс (84379) 30-1-48.

ПОСТАНОВЛЕНИЕ | КАРАР

Тел.: (84379) 30-1-48, факс (84379) 30-1-48.

16.11.2021 д. Канаш №8

Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлегенең
Канаш авылында гражданнарның үзара салым акчаларын кертү һәм
куллану мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләү турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль законның 25.1, 56нчы ст., «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» Татарстан Республикасы Законының 35нче ст., Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге Уставының 24нче статьясына туры китереп,

КАРАР БИРӘМ:

1. 2021нче елның 30нчы ноябренә Югары Ослан муниципаль районы Канаш авыл җирлеге гражданнарының үзара салым җыю мәсьәләсе буенча гражданнар җыенын билгеләргә.

2. Халык җыенына чыгарыла торган мәсьәләне расларга:
"Сез 2022 нче елда Югары Ослан муниципаль районының Канаш авыл җирлеге территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган кешедән 500 сум күләмендә үзара салым кертүгә һәм алган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә юнәлдерүгә килешәсезме?:

"Канаш авылының Үзәк урамы буенча юлга вак таш салу”
«ӘЙЕ» «ЮК»

3. Халык җыенын Канаш авылы, Центральная урамы, 32 нче йорт адресы буенча урнашкан торак йорт янында үткәрергә.
4. Халык җыенын Канаш авыл җирлеге Башкарма комитетына оештырырга.
5. Әлеге карарны Югары Ослан муниципаль районының рәсми сайтында, Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат рәсми порталында, шулай ук мәгълүмат стендларында урнаштырырга.

Югары Ослан муниципаль районы
Канаш авыл җирлеге башлыгы: Н.Н.Вальков